ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

04 08 2023 г. № 160

«Суүткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы» АҖ абонентларына 2024-2028 елларга агынты суларын агызу нормативларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктына, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы карары белән расланган Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу кагыйдәләренең X бүлегенә ярашлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 4 пункты белән, үзәкләштерелгән су чыгару системасына тискәре йогынтыны булдырмау максатыннан, Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Суүткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы» АҖ абонентлары өчен 2024-2028 елларга үзәкләштерелгән су агызу системаларына бүлеп бирелә торган агынты сулар күләме буенча нормативларны (җир өсте агынты суларын исәпкә алмыйча) тәүлегенә 50 куб.м. һәм аннан да күбрәк, кушымтага ярашлы рәвештә билгеләргә.

2. Карарга кушымтада күрсәтелгән абонентларда агынты суларны җитештерү технологиясе, составы һәм үзлекләре үзгәргән очракта, шулай ук абонент агынты сулар күләмен исәпләгәндә кулланылган зурлык белән чагыштырганда 10 проценттан артык үзгәргән очракта, әлеге карар белән расланган нормативлар агынты сулар күләме буенча нормативны билгеләү өчен каралган тәртиптә яңадан каралырга һәм үзгәртелергә тиеш.

3. Әлеге карарның 2 пунктында билгеләнгән күрсәткечләр үзгәргән очракта, карарга кушымтада күрсәтелгән абонентларга «Суүткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы» АҖгә мөрәҗәгать итеп, үзәкләштерелгән агынты су системаларына бүлеп бирелә торган агынты сулар күләме буенча су бүлеп бирүнең техник нигезләнгән нормативларын яңадан карап чыгу һәм формалаштыру өчен су бүлеп бирүнең исәпләнгән күләмнәрен бирергә тәкъдим итәргә.

4. Түбән Кама муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында һәм басма массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев

Татарстан Республикасы
Түбән Кама шәһәре
Башкарма комитеты карарына
кушымта
«04» 08 2023 № 160

Нормативы по объему отводимых в централизованные системы водоотведения сточных вод для абонентов АО «Водопроводно-канализационное и энергетическое хозяйство» с объемом отводимых сточных вод (без учета поверхностных сточных вод) 50 куб. м. и более в сутки

«Сууткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы» АҖ абонентлары өчен агынты су күләме белән (җир өсте агынты суларын исәпкә алмаганда) тәүлегенә 50 куб. м. һәм аннан да күбрәк үзәкләштерелгән агынты суларын агызу системаларына агызу күләме буенча нормативлар

| № п/п | Абонентларның атамалары | Агынты суның күләме | |
|---|---|---|---|
| | | куб. м/ел | куб. м/тәүлек |
| 1. | «Түбән Кама термалары» ҖЧҖ | 100 000,14 | 273,973 |
| 2. | «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» ДАССУ | 86 743,27 | 237,00 |
| 3. | «Конфи-Трейд» ҖЧҖ | 84 950,32 | 232,10 |
| 4. | Шәхси эшмәкәр Мустафин Р.М. | 69 075,54 | 188,73 |
| 5. | «Түбән Кама Нефтехим» ААҖ «Нефтехимик» УСК | 45 604,26 | 124,60 |
| 6. | «Перинаталь үзәкле балалар шәһәр хастаханәсе» ДАССУ | 76 477,78 | 208,96 |
| 7. | «Стройцентр-1» ҖЧҖ | 31 368,29 | 85,71 |
| 8. | «Түбән Кама икмәк комбинаты» ААҖ | 30 000,08 | 82,192 |
| 9. | «Камэнергостройпром» ҖЧҖ | 26 617, 76 | 72,73 |
| 10. | «Сәламәтлек комбинаты» ҖЧҖ | 24 002,88 | 65,58 |
| 11. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама районы буенча идарәсе | 21 514,68 | 58,79 |

* Халыкта барлыкка килгән агынты суларыннан тыш